Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№21 (114)

19 август 2014 ел




# Укытучылар җыелган җирдә . . .

«Әгәр укытучы эшен яратуын укучыларны яратуы белән берләштерә алса, ул – яңа заман укытучысы», – дип язган Л.Н.Толстой. Нәкъ менә шундый укытучыларны җыйды үзенә КФУның Алабуга институтында узган Мәктәп укытучыларының халыкара фестивале. Чараның ачылу тантанасында катнашкан КФУ ректоры Илшат Гафуров сәламләү сүзендә: «Фестиваль елдан-ел үсеш ала. Башта ул төбәкара булса, соңрак Россия күләменә күтәрелде. Хәзер исә Халыкара масштабта уза. Катнашучылар саны да арта бара. Быел алар 500дән артык булды», – диде.

## • Вакыйгалар эзеннән

Казан университетының **ХОР КАПЕЛЛАСЫ** 9-19 июль көннәрендә **РИГАДА** узган Бөтендөнья хор уеннарында (World Choir Games) **ҖИҢҮ ЯУЛАП**, туган уку йортына **АЛТЫН ДИПЛОМ БЕЛӘН КАЙТТЫ**. Әлеге уеннар ике елга бер тапкыр Җир шарының төрле континентларында үткәрелә торган чара. Быел анда 27000гә якын җырчы көч сынашкан. КФУның капелласын лаеклы җиңү белән тәбрик итәбез һәм алга таба да зур иҗади уңышлар телибез!

• • • •

**6 АВГУСТТА** Ватан космонавтикасы ветераны, КФУның астрономия һәм космик геодезия кафедрасы фәнни хезмәткәре, физика-математика фәннәре докторы **У.ЗАКИРОВКА** Ю.А.Гагарин исемендәге **АЛТЫН МЕДАЛЬ ТАПШЫРЫЛДЫ**. Бүләкләү тантанасы «Авиакосмик технологияләр, заманча материаллар һәм җиһазлар» VII Халыкара күргәзмәсе кысаларында уздырылган «Россия авиациясе һәм ракета-космик сәнәгатендә фәнни эшләнмәләрне булдыру һәм гамәлгә ашыру процессында нәтиҗәле чишелешләрне барлау» фәнни-гамәли конференциясендә башкарылды. Космосны үзләштерүдә үзенннән зур өлеш керткән галимгә Алтын медальне Космонавтика федерациясе вице-президенты, Советлар Союзы герое, очучы-космонавт А.Александров тапшырды.

• • • •

**14 АВГУСТ** көнне **КФУ** һәм Ростех дәүләт корпорациясенең **«РАДИОЭЛЕКТРОН ТЕХНОЛОГИЯЛӘР» КОНЦЕРНЫ** (КРЭТ) белән **ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ИТҮ ТУРЫНДА КИЛЕШҮ** төзеде. Чара «Машина төзелешендәге технологияләр – 2014» III Халыкара форум кысаларында узды. Әлеге килешү белем бирү программалары һәм тикшеренү проектларын гамәлгә ашыруда куелган көчләрне берләштерергә мөмкинлек бирә. Бу, үз чиратында, Россия һәм дөнья икътисадында конкурентлылыкка сәләтле югары технологияле, фәнни, хәрби һәм граждан-лык кулланылыш продукцияләре булдырырга ярдәм итәчәк. Килешүгә КРЭТ генераль директорының беренче урынбасары **И.НАСЕНКОВ** һәм КФУ ректоры **И.ГАФУРОВ** кул куйды. Хезмәттәшлек итү 2018 елның 31 декабренә кадәр көчендә булачак.

• • • •

Күптән түгел **КФУ** һәм **SAMSUNG ТИКШЕРЕНҮ ҮЗӘГЕ** мәгълүмати технологияләрнең алдынгы өлкәләрендә саналган фәнни һәм инновацион эшчәнлек алып барырга мөмкинлек бирә торган **КИЛЕШҮ ТӨЗЕДЕ**. Тикшеренү һәм эшләнмәләрне университетның Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты хезмәткәрләре башкарачак. Килешү ике елга дип төзелде һәм аның башлангыч этабында эшләр ике өлкәдә алып барылачак: профессор Р.Латыйпов җитәкчелегендә образларны тану өлкәсендә, профессор Е.Столов җитәкчелендә сөйләм идентификациясе технологияләре һәм тавыш файлының телен аерып чыгару мәсьәләләрен тикшерү өлкәсендә.

• • • •

Соңгы ярты ел эчендә КФУ Webometrics Бөтендөнья вузлары рейтингындагы күрсәткечләрен яхшырткан. 2014 елның июль ае күрсәткечләре буенча, **КФУ ДӨНЬЯВИ РЕЙТИНГТА – 1484 УРЫНДА**, Россия буенча – **17 УРЫНДА** тора. Ел башында исә ул дөньяда – 1888, Россиядә 22 урында иде.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

● Алабугада укытучылар фестивале

Студентларын җәйге ялга озаткач, уку йортлары бушап, моңсуланып калган шикелле була. КФУның Алабуга институтына мондый халәт таныш түгел, чөнки биредә күптән көтелгән Мәктәп укытучыларының халыкара фестивале узды.

# Укытучылар җыелган җирдә...

Чара 11 август көнне башланып, 4 көн буе дәвам итте. Фестивальнең географиясе дә киң: килгән кунаклар арасында, Россия белән бергә, Израиль, Германия, Төркия, Тайланд, Белоруссия, Швейцария, Казахстан вәкилләре һәм галимнәре дә бар.

Фестивальнең 12 август көнне узган тантаналы ачылышында КФУ ректоры **И.Гафуров**, мәгариф һәм фән министры **Э.Фәттахов**, РФ мәгариф һәм фән хезмәткәрләре профсоюзы рәисе урынбасары **Т.Куприянова**, республиканың мәгариф һәм фән хезмәткәрләрепрофсоюзкомитеты рәисе **Ю.Прохоров** катнашты. Шул ук көнне кунаклар Алабуга институты директоры **Е.Мерзон** белән очраштылар. Сәламләү сүзләреннән соң, Елена ханым катнашучыларны «КФУ – школе» проекты белән таныштырды. Ул үз чыгышында институтның мәктәп балаларына юнәлтелгән проектларына («ИнтелЛето» интеллектуаль-сәламәтләндерү лагере, татар телендә уздырыла торган «Хыял» лагере, «Балалар университеты», «Яңа буын укытучысы», «Җәйге физика-математика мәктәбе») аеруча басым ясады. Шулай ук Елена ханым кабул итү кампаниясе, аның икенче дулкыны һәм вуз студентлары алдында ачыла торган перспективалар турында да сөйләде.

Е.Мерзон фестивальдә катнашучылар өчен әзерләнгән өй эшләренә дә тукталды: «4 көн эчендә без сезнең конкурсларда, мастер-классларда ни дәрәҗәдә актив катнашуыгызны күзәтәчәкбез һәм ахырдан Мәктәп укытучыларының V халыкара фестивалендә иң актив катнашучыны аерып чыгарачакбыз».

Елена Ефимовна фестивальдә катнашучылар өчен әзерләнгән бүләкләрне дә күрсәтте: кабинет ишеген ачып керү өчен Мәктәп укытучылары фестивале логотибы төшерелгән брелок, укучыларга «бишле» билгесен кую өчен фестиваль логотибы төшкән ручка, Е.А.Ямбургның «Что принесет учителю новый профессиональный стандарт педагога» китабы. Әлеге китап белән бергә, укытучылар беренче өй эшләрен дә алды: алдагы көнне уздырылачак ачык лекциядә лекторга сораулар бирү һәм фикер алышу өчен китапны карап чыгарга кирәк иде.



■ Укытучылар өчен оештырылган бәйгеләр



■ О.Шатунова яулык бәйләү буенча мастер-класс уздыра

Мәктәп укытучыларының халыкара фестивале логотибы төшкән яулыкларны бәйләү буенча мастер-класс аерым кызыксыну уятты. Аны Алабуга институты доценты, педагогика фәннәре кандидаты **О.Шатунова** уздырды. Аның кулындагы яулык берничә мизгел эчендә ир-атлар өчен матур галстук яки муен яулыгына әверелде. Хатын-кызлар өчен исә чәчкә һәм муенга бәйләр өчен нәфис тасма ясау ысуллары күрсәтелде.

Чараны оештыручылар килгән кунакларны беренче көннән үк эш һәм биремнәр белән артык йөкләмәскә тырышып, аларга мәдәни ял тәкъдим итте. Көннең икенче яртысында укытучылар өчен шәһәр һәм музейлар буенча экскурсия оештырылды. Алабуга институтының төп бинасы янында фестиваль кунакларын уку йортының тарихы белән таныштырганнан соң, укытучылар, өч төркемгә бүленеп, шәһәр буенча сәяхәтләрен дәвам иттеләр. Һәр төркем күбрәк кызыксындырган һәм ошаган музейны сайлады. Алар арасында И.И.Шишкин өй-музее, М.И.Цветаева әдәби музее һәм Туган төбәкне өйрәнү комплекслары бар иде. Кунаклар өч сәгатькә якын шәһәргә беренче тапкыр килүчеләрне гаҗәпләндерә, элегрәк килүчеләрне яңадан тартып китерә торган Алабуга архитектурасына сокланды. Фестиваль кунаклары шулай ук күпсанлы мемориал һәм һәйкәлләр белән дә якыннан таныштылар. Әлеге экскурсиядә катнашучы һәркем бераз гына булса да гүзәл шәһәр Алабугага якынайды.



■ КФУ ректоры И.Гафуров мәгариф һәм фән министры Э.Фәттахов булачак 1 сыйныф укучыларына бүләкләр тапшыра

Төрле кызыклы вакыйгаларга һәм сюрпризларга бай булган 4 көннең үтеп китүе сизелмәде дә. Фестивальне оештыручылар, үзәккә мәктәп укытучысын куеп, алар өчен чын бәйрәм атмосферасы тудырды.

«Фестиваль көндәлеге» исемле бәйге өч көн буе дәвам итте. Укытучылар аның эшчәнлегендә бик актив катнашты, шуңа да жюрига җиңүчене билгеләү җиңел булмагандыр. Әлеге конкурста Түбән Кама шәһәренең 20нче мәктәбеннән рус теле һәм әдәбияты укытучысы, Яшь белгечләр советы рәисе **Дамир Юнысов** эше иң яхшы дип табылды.

Фестивальнең эшләү формасы урта гомуми белем бирү һәм югары һөнәри мәктәп, укытучы-практикантлар һәм укытучы-белгечләр арасындагы диалогка нигезләнеп көйләнде. Чараның эчтәлегендә принципиаль мөһимлекне гамәли юнәлеш – үз эченә актуаль темаларны алган мастер-класслар, эшлекле уеннар, түгәрәк өстәлләр тәшкил итте.

Фестиваль барышында барлыгы 60тан артык мастер-класс үткәрелде. Аларда укытучыларның һөнәри үсеше өчен мөһим һәм файдалы булган яңа идеяләр барлыкка килде, педагогик новацияләр кабул ителде, һөнәри һәм дустанә мөнәсәбәтләр булдырылды.

Чараның партнеры, «Новое образование» педагогик фәнни-методик журналның баш мөхәррире Е.Блинова мастер-классларда катнашкан 9 иң актив укытучыны үзенең журналына язылу белән бүләкләде.

Укытучылар бәйрәменең регламенты шулай ук укытучы һәм галимнәрнең формаль булмаган аралашуын, мәдәни программа һәм иҗади бәйгеләрне дә үз эченә сыйдырды. Мисал өчен, уку йортының коридорында флипчартлар урнаштырылды. Аларда тәкъдим ителгән темаларга үз фикереңне язып калдырырга мөмкин иде. Чараны оештыручылар биремнәрне берничә вариантта әзерләгәннәр: «Әгәр мин мәгариф министры булсам...» фразасын дәвам итәргә, «БДИ-2015» өчен сочинение темалары тәкъдим итү, ФШУ аббревиатурасын расшифровкалау һ.б. Җаваплар бик кызык һәм үзенчәлекле иде:

**ФШУ - фундаментально, шикарно, уникально!**

**ФШУ - фантастический шанс учителей!**

**ФШУ – фееричное шоу универсалов!**

**ФШУ – фанаты школы учителя.**

**ФШУ – файдалы шушы укулар.**

**ФШУ – формула школьного успеха.**

Иң яхшы расшифровка ясаучы булып Биектауның 1нче мәктәбе укытучысы **Г.Насыйбуллина** сайланды (**ФШУ – фейерверк шикарных уроков!**)

Инша темалары, шулай ук, үзенчәлекле дип табылды: «Мин Россия гражданины һәм моның белән горурланам», «Тормышымның нигезе – мәдәният», «Интернет. Минем дустыммы, дошманыммы?» Оештыручылар фикеренчә, иң яхшы теманы Чистай укытучысы **С.Хәйруллина («Күңелемне уятып җибәргән китап»)** тәкъдим итте.

Мәктәп укытучыларының халыкара фестивалено гомуми йомгак ясаганда, оештыручылар түбәндәге нәтиҗәгә килде: иң актив катнашучы булып Җәлил мәктәбе укытучысы Л.Нуртдинова билгеләнде. Аңа профсоюздан санаторийга юллама бүләк ителде. Абсолют җиңүче итеп Мамадыштан килгән Г.Чанышева танылды. Аңа КФУ ректоры И.Гафуровтан махсус бүләк – электрон китап, ТРның мәгариф һәм фән эшлеклеләр профсоюзы комитетыннан санаторийга юллама бүләк ителде.

Шушы сөенечле һәм куанычлы нотада Мәктәп укытучыларының V халыкара фестивале тәмамланды. Һәм инде икенче көнне үк киләсе елда булачак VI фестивальгә әзерләнү эшләре башланып китте.

*Материаллар Алабуга институтының Матбугат үзәге ярдәме белән әзерләнде*



■ Фестивальне ачу тантанасы

**Заман таләбе**

Фестиваль кысаларында укытучылар өчен төрле мастер-класслар оештырылды. Дәресрәге, аларны укытучылар үзләре оештырды. Алар эш тәҗрибәсе, яңа күнекмәләр, алымнар белән уртаклашты.

# Укытучылар да укый



## Үзлектән үсү – иҗат ул!

Профессор, психология фәннәре докторы **Леонид Попов** «Иҗат акты буларак үзлектән үсү» темасына мастер-класс үткәрде. Бирердә катнашучылар «Үз-үзең белән интервью» методы, сәләтле балалар өчен аларның кызыксынуына нигезләнгән проектлар эшләү алымнары белән якыннанрак таныштты. Леонид Попов сүзләренчә, үзлектән үсүгә эчке һәм тышкы факторлар ярдәм итә. «Алтын медальгә омтылып уңай сәләтләрен камилләштерүче дә, үзенең җинаятьчел күнекмәләрен камилләштерүче укучы да бер үк механизмга буйсынып эш итә. Әмма юнәлеш һәм нәтиҗә аерыла. Бу уңайдан укучыга кайсы юнәлештә хәрәкәт итәргә кирәклеген күрсәтеп җибәрү мөһим», – дип аңлатты профессор. Укучының материалны кабул итүе һәм аңлавы – иҗади акт. Укытучының материалны балаларга җиткерүе, үзенчә аңлатуы да иҗат. Заман телендә бу иҗатны эш программалары дип атыйлар. Ике очрак та бер үк нәтиҗә бирә – детерминация, үзеңне алга хәрәкәт иттерү, үзлектән үсү.




## Мәгариф системасы үссен дисәк…

Икенче бер мастер-класста Белоруссия дәүләт педагогика университетының педагогика кафедрасы филиалы мөдире, педагогика фәннәре кандидаты **Лидия Козинец** үзенең «Тикшеренүче» дип исемләнгән укыту-диагностика технологиясе турында сөйләде. Ул әлеге программаның төп этапларын атап үтте: гимназия укытучыларының сәләтле балалар белән эшләүгә әзерлек дәрәҗәсен өйрәнү, мөгаллимнәрнең нәзари базасын көчәйтү, программаның эчтәлек технологиясен булдыру һәм аны тормышта куллану. Лидия Козинец әйтүенчә, гимназия һәм университетлар хезмәттәшлеге иң беренче чиратта мәгариф системасы үсеше өчен кирәк. Мастер-класс конструктив-сөйләшү формасында узды, катнашучылар берберсенә сораулар бирде һәм бергәләшеп укытучы һәм галим хезмәттәшлегенең уңай нәтиҗәгә китерүе хакында фикер алышты. Шулай ук «Сәләтле баланы үстерү өчен мин ниләр эшлим?» дигән сорауга да җаваплар табылды.

## Киләчәк укытучысы нинди булыр?

Югары икътисад мәктәбе Мәгариф институтының мәгариф программалары Департаменты директоры **Александр Сорокин** тарафыннан үткәрелгән мастер-класста нәкъ менә шушы сорауга җавап эзләделәр. Киләчәк заманның һәр укытучысы нәтиҗәлелек, инновацион эшчәнлек, төпле белем яклы булачак. Шул ук вакытта ул хезмәттәшләре, директор һәм укучы белән һөнәри яктан яхшы аралашырга, мәгълүмат алышырга тиеш.

Александр Сидоркин Россия мәгариф системасының бик тиз үзгәрүе һәм шуның нәтиҗәсендә киләчәк укытучысына үзендә 3 шәп гадәт тәрбияләргә кирәклеген дә билгеләп үтте. Бу гадәтләр Tweaking-эшне ахырына кадәр җиткерү, Sharing-бүлешү, Stealing- «урлау»дан гыйбарәт. Соңгысы башкалардан үрнәк алу, ниндидер файдалы уй-фикерне үзләштерү белән бәйле. «Хезмәттәшләрдән нәрсәдер алып, үзләштереп, без диффузия процессын тизләтүгә ирешәбез», – дип белдерде Департамент директоры.





## «Юппи» буыны яки мәктәптә субкультуралар

КФУ мөгаллимнәре арасында да мастер-класс үткәрүчеләр шактый булды. Шуларның берсе – Алабуга институтының фәлсәфә һәм социология кафедрасы доценты, фәлсәфә фәннәре докторы **Альбина Гарифҗанова**. Ул катнашучыларга «Юппи» буыны үзенчәлекләре турында тәфсилләп сөйләде. Баксаң, «Юппи» буыны дип узган гасырның 70 еллар ахыры – 90 еллар башында туган шәһәр балаларын атыйлар икән. Бу балалар үсәргә ашыкмый. Социологлар фикеренчә, ничә яшь булуга да карамастан, алар үзләрен яшь дип саный. Балалар белән эшләгәндә, төрле субкультуралар, аларның килеп чыгу сәбәпләренә һәм үзенчәлекләренә аерым игътибар бирергә кирәк. Класста өстенлек иткән климатны билгеләү өчен исә аноним анкета сораштыруы уздырырга мөмкин. Бу сораштыруда сорауны дөрес итеп куя һәм нейтральлекне саклый белү зарур.



## Уңышка 7 секунд!

«Сыйныф җитәкчесе-2014» республика конкурсы җиңүчесе, Казан шәһәреннән рус теле һәм әдәбияты укытучысы **Диләрә Муравьева** «Конкурентлыкка сәләтле шәхес тәрбияләү» дип исемләнгән мастер-класс уздырды. Ул хезмәттәшләре белән ата-аналар җыелышы уздыру, «авыр» балаларның ата-аналары белән сөйләшү методикасы серләрен уртаклашты. Нәтиҗәдә һәр мөгаллимнең уңышка ирешү өчен 7 секунды барлыгы ачыкланды. Бу 7 секунд ата-аналар янына керүдән башлана икән. Укытучы кайда басып торырга тиеш? Ничек басып торырга тиеш? Нинди киемнән булырга тиеш? Ничек һәм нәрсә сөйләргә? Әлеге һәм башка бик күп сорауларга җентекләп җавап эзләнде. Бергәләп уздырылган «Минем җитешсезлекләрем», «Без синең белән шул яктан охшаган», «Безнең синең белән уртак якларыбыз бөтенләй юк» кебек тренинглар да укытучыларның күңеленә хуш килде. «Әгәр сезнең уңышка ирешәсегез килсә, сез үзегезне аңа ирешкән дип уйларга тиеш», – дип тәмамлады мастер-классын Диләрә Муравьева.

**Фестиваль турында**

*Ирина Игропуло, модератор, Себер-Кавказ федераль университеты:*

«Мин биредә беренче тапкыр. Шуңа күрә музейлардагы экскурсияләр аеруча күңелгә кереп калды. Фестивальне шундый югары дәрәҗәдә оештырганнары һәм уздырганнары өчен барысына да бик зур рәхмәт! Фестиваль миңа онытылмас хисләр, бик күп танышлар бүләк итте!»

*Гөлназ Таһирова, катнашучы, Казан шәһәре:*

«Мастер-классларда бик күп кызыклы әйберләр белдем. Алар искиткеч күңелле узды, тәҗрибә уртаклаштык. Монда килүемә бик шатмын. Алабугага беренче тапкыр килүем түгел. 17 ел элек мин биредә татар-инглиз теле бүлеген тәмамладым. Әнием дә биредә укыган. Шуңа күрә мин аңлатып булмаслык хисләр кичердем, яшьлегемә кайткандай булдым. Барлык оештыручыларга, катнашучыларга бик рәхмәтлемен».

*Галина Соколова, Татьяна Набалова, катнашучылар, Пермь шәһәре:*

«Безгә калса, фестивальдә катнашучылар ачыкларга теләгән һәр соравына җавап алгандыр. Үткәрелгән укулар кызыклы һәм әһәмиятле иде. Е.А.Ямбургның лекцияләрен бик зарыгып көтеп алдык, аның чыгышы безнең ышанычыбызны аклады! Н.Н.Савина, М.Левинның мастер-классларында булдык. Алар бүгенге көн өчен бик актуаль мәсьәләне күтәрде, чөнки сәламәтлекләре какшаган һәм төрле дәрәҗәдәге авырулары булган мәктәп яшендәге балаларның саны артканнан арта бара. Модераторларның дәресләренә, аларның югары дәрәҗәдәге һөнәри әзерлегенә һәм мастер-классларны оештыруда демократик стильне саклауларына сокландым. Күпсанлы фәнни-методик материал тәкъдим ителде, методика темасына багышланган күп мәсьәләләр хакында фикер алыштык. Идарә итү өлкәсендә эшләгәнгә (мәктәп директорлары), безгә ул әйберләрне белү зарури. Шулай ук университетның инновацион рәвештә, мәктәп укытучылары белән хезмәттәшлектә эшләүләре дә бик сөендерә. Фестивальне оештыручы һәм актив, креатив, кызыклы волонтерларга аеруча рәхмәт!».

● Сәнгать

# Укытучы һәм музыкант: максатлар бер!

**Фестивальдә катнашучы укытучылар өчен күп төрле чаралар уздырылды. Шулар арасында 12 август көнне «Визит» джаз оркестры уздырган концерт та мөгаллимнәр күңеленә хуш килде.**



«Визит» оркестры Татарстан халкын үз иҗаты белән 2007 елдан бирле сөендереп килә. Аларның дәртле чыгышларын чаллылылар гына түгел, ә Алабуга, Түбән Кама, Менделеевск, Казан джаз сәнгатен сөючеләр дә яратып кабул итә. Музыкантларның осталыгы турында тамашачылар фикере дә, аларның күп төрле конкурс-фестивальләрдә яулаган зур җиңүләре дә сөйли. Әйтик, 2007, 2008, 2009 елларда коллектив Бөтенроссия джаз башкаручылар конкурсында «Оркестр» номинациясендә лауреат дәрәҗәсенә лаек була.

Репертуарларының төп нигезен джаз стандартлары тәшкил итә. Ләкин биредә дә иҗади эзләнүләр музыкантларны гади булмаган импровизациягә этәрә. Нәтиҗәдә, танылган татар җырлары белән берлектә әзерләнгән программмалар барлыкка килә. Күп кенә татар халык һәм эстрада җырлары «яңача» яши, яңгырый башлый.

«Визит» оркестры фестивальдә катнашучы укытучылар алдында ел саен чыгыш ясый. Бу уңайдан оркестрның сәнгать җитәкчесе һәм төп дирижеры, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Владимир Завьялов та фикерләре белән уртаклашты. «Джаз – ул интеллектуаллар музыкасы. Ә укытучылар шушы категориягә карый, шуңа күрә алар безнең тамашачы. Кызганычка каршы, күпләр джазны аңламый. Ләкин безнең концертны караганнар джазга гашыйк була».

Оркестрның программалары күп төрле. Әйтик, «Яраткан кинофильмнарыбыз музыкасы» дигән проект белән чыгыш ясаганда, көйләр шул кинофильмнардан кадрлар белән бергә үрелеп бара. Шулай ук «Иртәгәге көн йолдызлары», «Балалар өчен джаз» программаларын да яратып кабул итәләр. Балалар өчен кварталга бер тапкыр лекторий – абонемент концертлар уздыралар. Анда кечкенә тамашачылар өчен музыкантлар, сәламәт яшәү рәвеше турында лекцияләр укыла.

Оркестр составындагы музыкантларның һәм фестивальдә катнашучы укытучыларның максатлары бер: музыкаль тәрбия һәм белем бирү! Аларның һәркайсына әлеге җаваплы хезмәтләрендә уңышлар һәм зур җиңүләр телибез!



# «Бик гади тарих»

**Халыкара фестивальнең өченче көнендә катнашучылар шулай дип исемләнгән спектакльне тамаша кылды.**

Спектакльне Яр Чаллының «Мастеровые» рус драма театры куйды. Спектакльнең исеменнән күренгәнчә, анда барган вакыйгалар чынлап та бик гади. Бер-берсен яратучы ике яшь йөрәк Даша белән Алексейның мәхәббәтенә ата-аналары каршы. Аларның мөнәсәбәтләре үсешенә үз эченә бикләнгән сыер, үзен генә яратучы әтәч, хыялый дуңгыз, зирәк ат һәм яхшы күңелле эт шаһит. Ярату хисләрен үз күзләре белән күргән хайваннар да сафлык һәм мәхәббәт турында уйлый башлыйлар. Ләкин бу халәт озакка бармый. Дашаның йөкле булуы турында әти-әниләре белеп ала.

Спектакльдәге вакыйгаларның беркемне дә битараф калдырмавы турында тамашачыларның күз яшьләре, 10 минутка сузылган көчле алкышлар сөйләде. Тамаша укытучыларны тагын да якынайтты, чөнки алар озак кына бергәләп тормыш фәлсәфәсенә корылган спектакль турында фикер алыштылар.






Фестивальнең өченче көне Сабантуй белән тәмамланды. Гади генә түгел ул, укытучылар анда үзләренең җыр-моңга, биюгә, сүз сәнгатенә оста икәнлекләрен күрсәтте.

# Җырлыйлар да, уйныйлар да!

Укытучы кеше нинди булырга тиеш? Акыллы, креатив, кабатланмас, сабыр һәм башкалар... Фестивальдә катнашучылар үзләренең бу сыйфатларга ия икәнлекләрен мастер-класслар вакытында кат-кат дәлилләделәр. Әле болар белән генә тәмамланмады: V халыкара мәктәп укытучылары форумында катнашкан мөгаллимнәр бик талантлы да булып чыкты. Кемдер бик матур итеп җырлады, кемдер биеде. Ә бер укытучы, фестивальгә багышлап, бик матур шигырь иҗат иткән иде.

Иҗади номерлардан тыш, чарада төрле уенбәйгеләр дә оештырылды. Укытучылар бу юлы да сынатып тормадылар, рәхәтләнеп уйнадылар, ял иттеләр. Тамашачылар да читтә калмады. Һәр чыгышны көчле алкышларга күмеп, конкурсларда да катнаштылар.

Сабан туеннан һәркем яңа уку елына җитәрлек көч-куәт алып киткәндәр дип уйлыйбыз.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.